*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре**
**2025-2026 нчы уку елы**
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 60**

**I. Тест биремнәрен эшләгез.**

1. Рәт гармониясе сакланмаган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   1) караңгы, әнкәй, алдынгы
   2) әлеге, тигез, җан
   3) фанилык, календарь, зәңгәрсу
   4) бураннар, урманнан, көннәр

2. Һәр сүздә дә [қ] авазы әйтелә торган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   1) көл, кәккүк, каты, түгәрәк
   2) колын, ачкыч, казлар, камыш
   3) күңел, кыяр, кәбестә, коңгырт
   4) көзге, көн, караңгы, келәт

3. Җөмләдәге хаталы сүз дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
*Беркадәр тынычлангач, ул Якубка көтелмәгән тәкьдим ясады.*
   1) беркадәр
   2) тынычлангач
   3) көтелмәгән
   4) тәкьдим

4. Эчтәлегенә карап, җөмләнең ахырын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Тормыш өзлексез көрәштән гыйбарәт:..... .*
   1) көн дә эшләргә кирәк.
   2) торасың да китәсең.
   3) көчлеләр ега, көчсезләр егыла.
   4) көрәшү кирәк.

5. Фарсы теленнән алынган кушымча булган сүзләр рәтен билгеләгез. **(2 балл)**
   1) даруханә, хәбәрдар
   2) мәктәп, әдәбият
   3) чәчәкле, сәламәтлек
   4) цивилизация, механизм

6. Җөмләдә *йөгән* сүзенең мәгънәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2**

**балл)**

*Атларын йөгән тезгененнән җитәкләп, печәнчеләрнең бер-бер артлы күпер аша чыгуы сәгатьтән артыкка сузылды (Н.Әхмәдиев).*

1) берәр нәрсә эшләүдән тыю, тоткарлый торган сәбәп
2) нәрсәгә дә булса җитәкчелек итү
3) әдәпсезлек, тыйнаксызлык
4 ) атның башына кидерелә торган авызлыклы, тезгенле җайланма

7. Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Үзегез күрәсез:бер тамчы яңгыр яуган юк. (Ш. Камал)*

1) иярчен аергыч җөмлә
2) иярчен ия җөмлә
3) иярчен тәмамлык җөмлә
4) иярчен вакыт җөмлә

8. Җөмләдәге алмашлыкларның төркемчәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. **(2 балл)**

*Кем идем димә, кем булырмын диген!* (Мәкаль)

1) зат алмашлыгы
2) сорау алмашлыгы
3) күрсәтү алмашлыгы
4) билгесезлек алмашлыгы

9. Сүзтезмәләр арасыннан фигыль сүзтезмәне билгеләгез. **(2 балл)**

1) безнең халык
2) быел кышын
3) хезмәте белән мактаулы
4) өстәл өстенә кую

10. *Ул - бурычын бишләтә кайтара торган кеше*. җөмләсендәге *бишләтә* сүзенең нинди сүз төркеменә каравын язгыгыз. **(2 балл)**

Җавап: ____________

## II. Теоретик бирем.

Сузык авазлар өлкәсендә очрый торган аваз үзгәрешләре турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. (**8 балл**)

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Сүз һәм андагы басымның урынын тәңгәллек белән күрсәтегез**,** җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| СҮЗ | БАСЫМ УРЫНЫ |
|---|---|
| А) пәрәмәч | 1) икенче иҗектә |
| Ә) бирешмәскә | 2) өченче иҗектә |
| Б) кайчаннан | 3) беренче иҗектә |
| В) кырмыскалар | 4) дүртенче иҗектә |
| Г) чишелешендә | 5) бишенче иҗек |

**Җавап : ________________________**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Мәкальләрнең ахырын уйлап языгыз. **(5 балл)**

*Егет сүзе* ________________________________________________________.

*Бер – алдыңа,* ____________________________________________________.

*Аз сөйлә,*__________________________________________________________.

*Җиде кат үлчә,* ___________________________________________________ .

*Туры әйткән – котылган,* __________________________________________.

2. Тексттны укыгыз һәм күп ноктaлар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Мин үзем икмәкне кеше өчен иң зарури ризык итеп кенә түгел, ә илнең иң зур байлыгы, дәүләтнең төп к...әте дип тә саныйм. Чыннан да, илдә, дәүләт кулында икмәк җитәрлек булмаса, халык тук, бөтен яши алыр идемени, дәүләт башка байлыкларын бүтән ихт...яҗларга тота алыр идемени?..

Халык икмәкнең дәрәҗәсен кытлык елларда гына түгел, ...әрвакытта, иң уңган чакларында да бик яхшы белгән. Ул аны юкка-барга әрәм-шәрәм

итмәгән, саклап токкан, ничек тә запас белән торырга тырышкан. Безнең татар халкында исә икмәккә хөрмәт аеруча зур иде. “Ипекәй” дип к...дерләп кенә йөртә иде ул аны... (*Әмирхан Еникидән*)

3. Текстта антонимик парлы сүзне күчереп языгыз. (**2 балл**)

___

4. *Байлыкларын* сүзен мәгънәле кисәкләргә аерып языгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагыз. (**4 балл**)

___

___

___

___

5. *“Ипекәй” дип к...дерләп кенә йөртә иде ул аны...* җөмләсендәге сүзләрне туры тәртипкә куеп языгыз. **(2 балл)**

___

6. Тексттан рус алынмасын күчереп языгыз. **(2 балл)**

___

7. *“Азның кадерен белмәгән күпнең кадерен белмәс”* темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)

___

___

___

___

___

___

___

___

___

___

___

___

___

___

___

___